**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 8 апрель | № 205

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләренең һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында» 2015 ел, 16 июль, 518 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «2015 елның 24 июленә кадәр» сүзләрен «2016 елның 30 маена кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «2015 елның 30 октябренә кадәр» сүзләрен «2016 елның 30 маена кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 5 пункты нигезендә муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен булдыруны һәм раслауны тәэмин итүне, аларны кулланып, 2017 елга (2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның планлаштырылган чорына) муниципаль йөкләмәләрдән башлап, муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга муниципаль йөкләмәләр булдыруны тәкъдим итәргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 12 сентябрь, 666 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 ноябрь, 907 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктта «алты ай эчендә» сүзләрен «2016 елның 1 октябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин

итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.»;

6 пунктта «2017 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков